**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**КЛЯШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422377 Тетюшский район, с.Кляшево, ул.Ленина, 12А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕЛӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422377 Тәтеш районы, Келәш авылы,Ленин ур, 12А

тел. (84373) 5-60-39, факс 5-60-39, e-mail: Kls.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606559150, ИНН/КПП 1638001617/163801001

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**24 .07. 2023** **№ 30-1**

**" Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына үз керемнәре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында Карар кабул итү тәртибе турында» «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге Советының 15.06.2020 № 59-2 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Келәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында Карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 пунктның 2 абзацында, 4 пунктта, 5 пунктның 2 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1 һәм 3 абзацларында "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен»Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) " сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисенә)»дигән сүзләр белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге территориясендә мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга http://tetushi.tatarstan.ru/ һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында " (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар аның басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге башлыгы Галимов Фәнил Хәлим улына йөкләргә.

**Җитәкче** **Ф.Х.Галимов**